**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 4 июнь № 407

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 29 март, 199 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык түбәндәге өлкәләрдә вәкаләтле орган булып тора:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«инновация эшчәнлеге;

конкурентлыкны үстерүдә булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.82[1] нче пункт өстәргә:

«4.1.82[1]. Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне мониторинглау, дини һәм милли җирлектәге бәхәсләрне алдан кисәтү комплекслы программасы кысаларында, үзенең компетенциясе чикләрендә мәгълүмат җыюны һәм аны дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мәдәният тармагында мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасының башкарма хакимият органына тапшыруны тормышка ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\407.docx